
# Равил Фәйзуллинга 70 яшь

- Инешләрнең башы чишмә булыр.
- Яхшылыкның асылы – тугрылык.
- Яшәү – бәхет: илең синең өчен,
  Син – ил өчен булсаң горурлык.




* “... Бистәнең син газиз бер улыдыр,
Татарымның даны һәм шаны.
Үз исемен алтын белән язган
Шигърияткнең олуг бер ханы.”

(Вәзыйх Фатыйхов)



Фәйзуллиннар гаиләсе. Сулдан беренче Равил, әнисе Әминә апа, энесе Рөстәм, әтисе Габдрахман ага, сенлесе Люция, абыйсы Рафаэль. 1953 ел.

Әтисе Габдрахман абзый һәм әнисе Әминә апа, бу нарасыйның киләчәктә татар шигъриятен таң калдыручы олпат ир булачагын күңелләренә дә кертмәгәннәрдер. *Ләкин* сизенгәннәрдер, әти-әнисенең теләгән изге теләкләре аңа гомер буе юлдаш булырлар.





Башлангыч сыйныфларда Равил абыегыз укыган мәктәп. Балык Бистәсе районы, Балтач авылы.

- «Мин Бөек Ватан сугышы вакытында, 1943 нче елның 4 августында тудым. Ерткыч фашистлар армиясе бу вакытта безнең илебезгә, төрле яктан һөҗүм иттеләр. Ниһаять,сугыш бетте. Совет армиясе дошманны җиңде. Безнең Совет халкы сугышта җимерелгән төзелешләрне сугышка кадәргегә караганда да яхшырак итеп эшләде. 1950 елның көзе җитте. Мин беренче класска укырга кердем һәм беренче классны «отлично»га бетереп чыктым.
- Шулай ук икенче класста, 1951-52 нче уку елын да «отлично» билгесенә тәмамладым.
- Һәм өченче класста укыганда өч фәннән «4»ле билгесе, ә калганнарыннан «5»ле чыкты. Шулай итеп өченче классны «4»ле һәм «5»ле билгеләренә укыдым.
- Мин дүртенче класста тагын да тырыштым һәм дүртенче классны «отлично»га тәмамладым. Хәзер бишенче класста укыйм. Быел да «отлично»га укырга тырышам. Мин шагыйрь булырга хыялланам. Һәм шулай итеп мин беренче мәртәбә «Чаңгы шуганда» исемле кечкенә шигырь яздым.»
- 10ноябрь 1954 ел. ТАССР Кызыл Йолдыз районы, Юлсубино (Балтач) авылы.



Максаты булган кеше – көчле кеше.

**Яхшы сүз**

*Әйт кенә тәмле сүз -иркәләр күпме күз!*

*Әйт кенә яхшы сүз -Һәркемдә көләч йөз!*

**Җиләк кайда күп?**

*Әти, әни, мин - өчәү йөрибез аланда.* Җыябыз *җир җиләк үләнне аралап.*



1965 ЕЛДА КАЗАН ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ТАРИХ-ФИЛОЛОГИЯ ФАКУЛЬТЕТЫН ТӘМАМЛЫЙ. КӨНДЕЗГЕ БҮЛЕКТӘ УКЫСА ДА, УЛ ИКЕ ЕЛДАН АРТЫК ТӨРЛЕ ГАЗЕТА-ЖУРНАЛ РЕДАКЦИЯЛӘРЕНДӘ («ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ» (ХӘЗЕРГЕ «САБАНТУЙ»), «ЯЛКЫН» Һ.Б.) ЭШЛӘП АЛА. БЕРНИЧӘ ЕЛ ДӘВАМЫНДА УНИВЕРСИТЕТНЫҢ ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕН ҖИТӘКЛИ. УКУЫН ТӘМАМЛАГАЧ, «СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ» (ХӘЗЕРГЕ «КАЗАН УТЛАРЫ») ЖУРНАЛЫНДА БҮЛЕК МӨДИРЕ ВАЗИФАСЫН БАШКАРА.

- 1968-1972 нче елларда Татарстан Язучыларының Әлмәт оешмасы җитәкчесе, 1973 елдан 1977 елның январенә чаклы Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы секретаре булып эшли. 1989 нчы елда аны “Казан Утлары” журналының баш мөхәррире итеп билгеләп куялар. Бер үк вакытта 1990-1995 нче елларда Татарстан Югары советы депутаты да булып тора.
- 1999 нчы елда Татарстан Президенты Указы белән, дүрт томлык “Сайланма әсәрләр”е өчен, “Татарстанның халык шагыйре” дигән олуг исем бирелә.

**Язсам гына яшәвемне раслыйм.**
**Юньле эшем – йөзем аклыгы.**
**Язсам гына – Җирең улы булып**
**сөелүгә – назга хаклымын.**
**Язсам гына – бәхетем тулы, бөтен.**
**Язу эше – намус, кан эше.**
**Язсам гына – илгә, кешеләргә**
**файда итсәм генә, мин – кеше!.**


Р.Фәйзуллин

-25, РУС ТЕЛЕНДӘ 12 КИТАБЫ ЧЫККАН. АНЫҢ ТУРЫНДА 300 ДӘН АРТЫК ХЕЗМӘТ (МӘКАЛӘ, ИЖАТ ПОРТРЕТЫ, РЕЦЕНЗИЯ ЯЗЫЛГАН) АЕРЫМ ӘСӘРЛӘРЕ АЛМАН, ГАРӘП, ИНГЛИЗ, ПОЛЯК, ФРАНЦУЗ, ТӨРЕК, ЭСТОН, ҮЗБӘК, ГРУЗИН Һ.Б. ТЕЛЛӘРГӘ ДӘ ТӘРҖЕМӘ ИТЕЛӘ. АНЫҢ ШИГЫРЬЛӘРЕ ИКЕ ЙӨЗ ТОМЛЫК «БӨТЕНДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЛАРЫ КИТАПХАНӘСЕ» СЕРИЯСЕНДӘ ЧЫККАН ТОМЛЫКЛАРНЫҢ БЕРСЕНДӘ (180) УРЫН АЛА. ӘДИПНЕҢ ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНДА ИКЕ ТАПКЫР «САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР»Е (БИШТОМЛЫК — 1992-2001 ЕЛЛАРДА; АЛТЫТОМЛЫК — 2005 ЕЛДА) БАСЫЛЫП ЧЫГА.

* “... Миллəтен ул байрак итə -
Шуңа зурлыйм мин аны.”      ( Г. Ахунов)

- **“Он лепит образ, и его мысль движется, обгоняя строку…”**
- **(Флор Васильев, удмурт шагыйре)“**

**“Равиль Файзуллин – мастер высокого класса, смелый реформатор татарского стиха, новатор,…”**
**(Александр Губарь, украин язучысы)**




**Шигърият дуслыгы – халыклар дуслыгы.**
Сулдан уңга – балкар шагыйре **Кайсын Кулиев**, **Равил Фәйзуллин**, **Хәсән Туфан**, рус шагыйре **Сергей Орлов**. 1976 ел.



Сулдан уңга – утырганнар: композитор **Сара Садыйкова**, шагыйрь **Сибгат Хәким**; басып торалар – язучы **Гариф Ахунов**, җырчы **Вафирә Гыйззәтуллина**, шагыйрь **Равил Фәйзуллин**. 1981 ел.




**Равил Фәйзуллин** бөек сынчы **Бакый Урманче** белән. 1985 ел.



Шагыйрь **Равил Фәйзуллин**, композитор **Нәҗип Җиһанов**, режиссер **Ширияздан Сарымсаков**. 1980 ел.

*ЙӨР, КҮР, БЕЛ СИН КҮП ҖИРЛӘРНЕ, КҮП ИЛЛӘРНЕ. САУ ҖАНЫҢАҺӘРБЕР ТАРАФ ЯКЫН БУЛСЫН. КҮЗЕҢ КҮРГӘН ҺӘР МАТУРДАН, ҺӘР ЯҢАДАН КҮҢЕЛЕҢӘ ХИКМӘТ КУНСЫН, АКЫЛ КУНСЫН. ДӨНЬЯ ЗУР УЛ: ШӘП БАЛКЫШЛАР БИК КҮП ОЧРАР. (ЕГЕТЛЕГЕҢ СЫНАЛЫР ДА ИНДЕ ШУНДА!) ҺИЧ КҮЛӘГӘ ТӨШЕРМӘ СИН ҖАНЫҢДАГЫ ТУГАН ИЛЕҢ, ТУГАН ҖИРЕҢ ЯКТЫСЫНА!*


Египет. 1996 ел.




Германия. 1995 ел.


Мальта. 1997 ел.



Шотландия. 1997 ел.


Пакистан. 1998 ел.




- *...Бүген юл бик уңмады. Тота идек тотуын -*
  *
- *урыны җай булмады! Без утырган тугайлыкка җиле уңай булмады...*
- *Иртәгә тотарга калды бүгенгесе өчен дә. Әйтик, берәр чиләк -унлап сыла, алты чуртан, ундүрт бәртәс..* Малай чакта, бәлки.әлләни тота алмагандыр, әмма зур үскәч байтак эре балыклар эләктерде ул

**Әй яшь чаклар! Яшь чаклар! Кесә тулы борчаклар! Саламнан тәртә каерып чикерткә җыккан чаклар!**




Аның Алмаз дигән нәни улы әлегә кырмыскалар көрәштерә.




Менә ул да үсеп җитте, солдат сафларына китте.

*Очтылар бер-бер артлы. Җитезләр! Кош кебекләр! Кирәк - җирдә, кирәк - күктә дан*








Идел уртасы – гомер уртасы.
Равил абыегыз улы Алмаз, туганы Илдар белән.



- Аның әсәрләре күп мәртәбәләр төрле дәрәҗәдәге премияләр, аерым алганда: 1966 елда яшь шагыйрьләрнең Мәскәүдә ВЛКСМ ҮК оештырган Бөтенсоюз фестивале премиясе, 1970 елда «Мәрмәр» исемле китабы өчен Республика яшьләр оешмасының М.Җәлил исемендәге премиясе, 1973 елда «Дружба народов» журналы һәм 1979 елда «Литературная Россия» газетасы премияләре, 1978 елда «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы (1976) өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1999 елда Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев Указы белән аңа «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән исем бирелә. 1985 елда аңа «РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелә. Әдәбиятны үстерүдә һәм матбугаттагы казанышлары өчен Р.Фәйзуллин 2006 елда Дуслык ордены белән бүләкләнә. 2007 елда Татарстан Фәннәр академиясенең мактаулы академигы итеп сайлана